ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2022 г. Казань № 270-7/э-2022

«РЖД» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-11/э карары белән билгеләнгән озак сроклы индивидуаль тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 28 октябрендәге 33-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2023 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «РЖД» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр

оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2020-2021 елларга индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 3-11/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2020 № 445-17/э-2020, 17.11.2021 № 279-10/э-2021 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-11/э
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28.10.2022 № 270-7/э-2022
карары редакциясендә)

2020 елның 1 гыйнварыннан башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә «РЖД» ААЖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә индивидуаль тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «РЖД» ААЖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе – Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясе – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 113 851,67 | 56,67 | 0,39450 | 113 851,67 | 56,67 | 0,39450 |
| | | 2021 | 113 320,52 | 62,57 | 0,39883 | 113 320,52 | 62,57 | 0,39883 |
| | | 2022 | 137 978,39 | 66,22 | 0,47565 | 137 978,39 | 66,22 | 0,47565 |
| | | 2023 | 127 768,62 | 73,78 | 0,45354 | 127 768,62 | 73,78 | 0,45354 |
| | | 2024 | 133 018,37 | 63,78 | 0,45849 | 133 018,37 | 63,78 | 0,45849 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 3-11/э
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28.10.2022 № 270-7/э-2022
карары редакциясендә)

«РЖД» ААҖ филиалы – Трансэнерго структур бүлекчәсе –
Энергия белән тәэмин итү буенча Горький дирекциясенең 2020-2024 елларга (югалтуларны исәпкә алмыйча) кирәкле тулай кереме

| Т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | Энергия белән тәэмин итү буенча Горьков дирекциясе – Трансэнергоның структур бүлекчәсе – «РЖД» ААҖ филиалы | 2020 | 34 307,92 |
| | | 2021 | 31 341,18 |
| | | 2022 | 37 326,13 |
| | | 2023 | 36 642,23 |
| | | 2024 | 40 083,59 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге